| СОВЕТ ДРОЖЖАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЧҮПРӘЛЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ |
|---|---|---|

| **РЕШЕНИЕ** | с.Старое Дрожжаное | **КАРАР** |
|---|---|---|

2023 елның 5 мае № 28/6

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында» Федераль законның 2 һәм 3 статьяларына һәм Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 18 мартындагы 71-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 15 декабрендәге 14/9 номерлы (03.02.2022 № 16/3, 28.03.2023 № 27/6 редакциясендә) карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.2 пунктында:**

беренче абзацта «энергетика нәтиҗәлелеген арттыру хакындагы законнарда» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турындагы законнарда» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле **12 пунктча** өстәргә:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эчендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр.»;

**1.6 пунктының 1-3 пунктчаларында** «1-11» саннарын «1-12» саннарына алмаштырырга.

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставы нигезендә рәсми басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы Башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе М.Р. Гафаров